**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1041

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина тикшерүен оештыру турында» 2012 ел, 13 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина тикшерүен оештыру турында» 2012 ел, 13 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1060 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәтнамә, яисә торуга рөхсәт, яисә эшләү өчен рөхсәтнамә бирүдән баш тарту яки аларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып торган йогышлы авырулар исемлеге турында» 2010 ел, 2 апрель, 188 нче карарын» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәтнамә, яки торуга рөхсәт, яки патент, яки эшләү өчен рөхсәтнамә бирүдән баш тарту яисә аларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып торган йогышлы авырулар исемлеген, шулай ук аларның булуын яки булмавын раслау тәртибен, әлеге авыруларның булуы (булмавы) турында медицина бәяләмәсе формаларын раслау хакында» 2015 ел, 29 июнь, 384н боерыгын» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина тикшерүен үткәрүне

гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе, Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмалары, чит ил гражданнарын эшкә җәлеп итүче оешмалар һәм социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибендә:

4.1 нче пунктта «фтизиатрны» сүзеннән соң «инфекционистны» сүзен өстәргә; «лаборатория тикшерүе ысуллары» сүзләреннән соң «, шул исәптән кешенең организмында наркотик чаралары, психотроп матдәләр һәм аларның метаболитлары барлыгына химия-токсикология тикшеренүләре» сүзләрен өстәргә;

4.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Медицина оешмалары чит ил гражданын һәм гражданлыгы булмаган затны түбәндәге документлар булганда кабул итәләр:

1) шәхесне таныклый торган документлар;

2) Россия Федерациясенә виза алуны таләп итмәгән тәртиптә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга миграцион карта һәм аның күчермәсе (булган очракта);

3) виза һәм аның күчермәсе (Россия Федерациясенә виза алуны таләп иткән тәртиптә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга);

4.6 нчы пунктта «медицина тикшерүен раслау документларын» сүзләрен «әлеге чит ил гражданында накромания авырулары булмауны раслаучы документларны һәм кешенең организмында наркотик чаралары, психотроп матдәләр һәм аларның метаболитлары барлыгына һәм әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәтнамә, яки торуга рөхсәт, яки патент, яки эшләү өчен рөхсәтнамә бирүдән баш тарту яисә аларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып торган йогышлы авырулар барлыгына химия-токсикология тикшеренүләрен үз эченә медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча бирелгән документларны, шулай ук әлеге чит ил гражданында кешенең иммунодефицитлык вирусы (ВИЧ-инфекция) барлыкка китерә торган авырулар булмау турында шаһәдатнамәне»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга медицина тикшерүен үткәрүне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе, Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмалары, чит ил гражданнарын эшкә җәлеп итүче оешмалар һәм социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибенә теркәлгән кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 ___ елның ____ ае өчен
Татарстан Республикасы территориясенә кергән чит ил гражданнарында
һәм гражданлыгы булмаган затларда булуы ачыкланган
әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган йогышлы авырулар,
шул исәптән кешенең иммунодефицитлык вирусы (ВИЧ-инфекцияләр)
барлыкка китергән авырулар һәм наркомания авырулары саны турында
мәгълүматлар (арта барган нәтиҗә белән)

| Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган йогышлы авырулар, шул исәптән кешенең иммунодефицитлык вирусы (ВИЧ-инфекцияләр) барлыкка китергән авырулар һәм наркомания авырулары исеме | Медицина тикшерүе үткән затлар саны | Авыру очраклары ачыкланган (абсолют сан) | Госпиталь-ләштерелгән | Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә очраклар саны турында хәбәр ителгән |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Кешенең иммунодефи-цитлык вирусы (ВИЧ) барлыкка китергән авыру | | | | |
| Кешенең иммунодефи-цитлык вирусы (ВИЧ) барлыкка китергән симп-томсыз инфекция статусы | | | | |
| Лепра (Гансен авыруы) | | | | |
| Туберкулез | | | | |
| Сифилис | | | | |
| Наркомания авыруы». | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1041.docx